| | |
| --- | --- |
| СОВЕТ<br>Кучуковского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Көчек авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2020 Түбән Көчек авылы № 5-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварендәге 44-1 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2020 елның 27 октябрендәге 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында 347-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварендәге 47-1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 бүлектәге 11.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тудырмыйлар.»;

1.2. 16.3 пунктының 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

1.3. 20 бүлекнең 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган

чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү.».

2. 2019 елнын 31 гыйнварендэ 44-1 номеры белэн расланган «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Көчек авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»гы карарын Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының 2020 елның 22 октябрендәге 3-1 номерлы карары белән үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.НУРМӨХӘММӘТОВ